# СОЛДАТ

## I

Садыйк ашыга-ашыга ат җигеп двордан чыкканда часть сәгате өчне сукты. Ул артындагы энесенә әйләнеп карады да атына сугып чабарга тотынды. Күп йөрүдән казылган урамда арба әле бер якка, әле бер якка кагылганга, Садыйкның арбасында әйберләр төрлесе төрле якка сикерә, Садыйк үзе дә бер алга китеп, бер артка китеп, исерек кеше кебек селкенә башлады. Менә озак үтмәде, шәһәрне чыктылар. Садыйк, атын туктатып, яңадан арбасындагы әйберләрне рәтләп куйды. Янындагы карбызны алып арбаның үрәчәсенә сугып ярды да бер кисәген арттагы арбадагы энесенә бирер өчен: «Закир! Закир! Уз! Уз!», — дип кычкыра башлады. Закир да килеп чыгып атлатып кына узды, ул да арбасын рәтләргә туктады. Ул туктагач, Садыйк карбыз берлә калачны күрсәтеп: «Мә! Ал!» — дип кычкырды. Закир карбыз алырга килгәндә Садыйк: «Бик кызу кайтма, атыңны яктыда эчермә, мин йоклыйм», — дип, карбыз ашарга тотынды, атлар кузгалды. Ул яхшылап утырганның соңында кесәсен тотып карады. Кулы катыга тигәч, акчасы югалмаган икән дип, күңеле тынычлап карбызны ашарга дәвам итте. Менә тагы күңеленә әллә нәрсәсе калган кебек булып китте. Базарда алган нәрсәләрен барысын да уйлады. Кулы берлә капчыкны капшап карарга тотынды, кулына зур такта чәй берлә шикәр тиде. Аның артыннан әллә нинди йомшак нәрсәгә кулы бәрелде, анысы сеңеленә алган күлмәк икәнлеге исенә төште. Аның артыннан каеш йөгән, чырабчак кулына тиде. Капчык төбендә балаларга дип алган алмалар тәгәри башлады. Ул: «Юк, болар берсе дә түгел! Боларга башка бер бик кирәкле әйберем бар иде», — дип, кирәкле әйберен эзләргә тотынды. Үзе карбызны арчып бетереп, авызын сөртер өчен тирәли чиккән ак яулыкны алырга кесәсенә тыгылды. Авызын сөрткәндә кулы яулыкның чиккән кырыйларына тиде, кылт итеп күңеленә Гайнижамал килеп

төште. Әйе, бу яулык Гайниҗамал яулыгы ич! «Гайниҗамал яулыгы, Гайниҗамал яулыгы!» — дип, шул уйдан үтә алмаенча, шул уйда катты. Аның авызында «Гайниҗамал» дигән сүз әвәләнә башлады. Ул үзенең югалган нәрсәсенең Гайниҗамал берлә ни мөнәсәбәте барлыгын хәтеренә китерү өчен үзенең башыннан әллә нәрсәләр эзләргә тотынды, аның күңеленә кичә сыер азбарында Гайниҗамал берлә күрешүе, Гайниҗамал берлә сөйләшүе, аларның сөйләшкәндә бертуктамаенча сыерның күшәве хәтеренә төште. Гайниҗамалның Садыйкны кысып кочаклавы, авызыннан үбүе күңеленә килде. Ләкин югалган нәрсәсенең Гайниҗамал берлә мөнәсәбәте һаман табылмады. Ул тагы тырышып уйларга тотынды. Шул ара да булмады, арба базга төшкән күк бик катылык итте. Садыйк урыныннан селкенеп китте, бу селкенү Садыйкның уйларын бөтенләй икенче тарафка агыза башлады. Кылт итеп аның күңеленә бүләк килеп төште. Садыйк әллә ничә ел эзләгән нәрсәсен тапкан кебек «бүләк, бүләк» дип үзеннән үзе сөйләнергә тотынды. «Бүләк, бүләк! Гайниҗамалга бүләк!» — дип бик тиз кесәләрен актарырга тотынды. Озак үтмәде, ул кечкенә генә кәгазь савыт берлә кунага салган сабынны кесәсеннән өстерәп чыгарды. Ул, үзенең суга батып үлә торган баласын судан тартып чыгарган кеше кебек шатланып, кәгазь савыт берлә сабынны карарга тотынды. Икесен дә төрле яктан әйләндереп караганның соңында әллә нинди әҗәл даруын саклаган кеше кебек күкрәк кесәсенә тыгып куйды.

Бу нәрсәләрне карау, аларны җыеп кую Садыйкка әллә нинди үзенә бертөсле шатлык бирде. Ул үзенең күкрәгендә әллә нинди бик кадерле, аңарга бик якын нәрсә барлыгын хис итте. Ул шул шатлык берлә шатланып Гайниҗамалны уйларга тотынды. Үзенең Гайниҗамал берлә сөешүе, Гайниҗамал берлә бер елдан бирле сөешүе, Гайниҗамал берлә әле азбарда, әле су юлында күрешүләре, Гайниҗамал берлә бер берсеннән аерылышмаска вәгъдә кылышулары күңеленә төште. Ул Гайниҗамалдан аерылмаска үзенә үзе вәгъдә кыла башлады. Гайниҗамал берлә тагы күрешүләрне, Гайниҗамал берлә кияүле-бикәчле булып йөрүләрен, Гайниҗамал берлә ирле-хатынлы булып торуларын, Гайниҗамал берлә бала-чага атасы булып гомер итүләрен

уйлый башлады.

Аның күзенә озын буйлы, кара күзле, кара сачле, тулы йөзле Гайниҗамал күренгән кебек булды. Аның күңеленә Гайниҗамалның шул кара күзләрен кызартып, кара керфекләрен юешләтеп яше аккан кебек булды. Ул Садыйкка карап: «Булмас, булмас!» — дип, башын селкеткән кебек булды. Садыйкның матур уйлары бердән югалды. Аның күңеленә әллә нинди ямьсез уйлар килә башлады. Күз алдын томан каплаган кебек булды. Гайниҗамал шул томан эчендә аз гына күренә башлады. Озак узмады, ул бөтенләй югалды. Менә шып итеп ат туктады.

Садыйк әллә ни булган кебек селкенеп китте. Күңеленә быел солдатка каралуы килеп төште. Ул башын күтәреп алга карарга өлгермәде, энесе: «На!» — дип кычкырып, атын куарга тотынды. Садыйкның да аты кузгалып китте.

Аның уйлары бөтенләй башкарды, ул үзенең солдатка каралуы тугрысында уйларга тотынды. Аңарга аны алырлар төсле күренә башлады, аны авылыннан аерып, йортларыннан аерып, бигрәк Гайниҗамалдан аерып, әллә кая еракка озатырлар кебек күренде. Ул үзен үзе солдат итеп уйлый башлады. Ул үзен үзе зур казармада әллә никадәр соры шинельләр кигән егетләр арасында, әллә никадәр аталарыннан-аналарыннан, үзләренең сөйгән Гайниҗамаларыннан аерылган солдатлар арасында күргән кебек булды. Тагы аның күзенә Гайниҗамал күренә башлады. Тагы ул үзен аның кочагында кебек хис итте. Атның туктавы аны тагы уятты. Ул үзен су уртасында күреп бакчага җиткәнлеген белде. Атны, су эчермәс өчен «На!» дип кычкырды. Ат тагы кузгалып китте. Ул урынын рәтләп, дилбегәсен бәйләп, йокларга ятты. Бик озак аның күз алдында әллә нинди солдатлар, эфисәрләр күренгән кебек, бик озак аның янында аның кочагында Гайниҗамал яткан кебек булды, бик озак аның берлә Гайниҗамал арасында әллә нинди җитә алмаслык җир бар кебек, үтә алмаслык су бар кебек күренде. Шул уйлар, шул исәпләр берлә Садыйк йокыга китте.

## II

«Туу!!» дигән тавышка Садыйк уянып китте. Күзен ачу берлә үзенең кайтып җиткәнлеген белеп торып утырды. Ул уйларга да өлгерә алмады, майламаган капка шыгыр итеп бик көйләп ачылды. Садыйкның аты кузгалып йортка керде. Садыйкларга каршы бөтен өй җәмәгатьләре йөгереп чыкты. Әтисе атларны муеннарыннан тотып карап, кызу кайтуларын-кайтмауларын белгәннән соң: «Исән кайттыңызмы, оланнар (угланнар)?» — диде. Садыйк арбадан төшеп: «Аллага шөкер, сары алашада 26 пот булды, биядә 24 пот та 11 кадак, 52 шәр тиеннән бушаттык», — диде. Шул арада кечкенә кызлар: «Абзый, алма! Абзый, алма!» — дип, әле Садыйк янында, әле Закир янында әйләнә башладылар. Миңлеҗамал абыстай угылларын күрү берлә тиз генә самавырга ут салды. Закир берлә Садыйк атларны туарып, арбаларны лапас астына кертеп өйгә кергәндә, самавыр да кайнап өлгерде. Әхмәт абзый да кызулана-кызулана тәһарәтен төзеп бетереп, ахшамга барырга хәзерләнә башлады. Садыйклар керү берлә ул чалмасын киеп: «Акчаны мин намаздан кайткач бирерсез», — дип, ашыга-ашыга чыгып китте. Садыйк берлә Закир чәй эчәргә утырдылар. Садыйк, ниләр алганны барысын да күңеленнән үткәреп, әтисенә хисап бирергә хәзерләнде. Тагы кершән берлә сабынга килеп җитте. Аларга киткән 45 тиен расхутны төрлесен төрле нәрсәгә бүлеп үзенең бухгалтериясен тәмамлады. Ләкин кершән-сабын тагы моның күңелендә әллә нинди хисләр уяндырды. Ул тагы әллә нәрсәдән курыккан кебек булды. Әллә нинди өметеннән өзелгән [кебек] булды. Тагы аның күңеленә үзенең быел каралуы, үзенең бер-ике айдан солдатка алынып әллә кая китүе, үзенең шул гөрләгән өйдән, шул самавырдан, шул йорттан, шул сары алашадан, шул сабыннар хуҗасы Гайниҗамалдан аерылуы хәтеренә килде. Ул бик озак ясаган чәйне эчмәенчә, күзен бер урыннан алмаенча уйларга тотынды. Ул төрле нәрсә тугрысында уйларга теләде, төрле юл берлә үзенең күңеленнән шул ямьсез солдатлык уен җибәрергә тырышты. Ләкин ни генә уйласа да, һәр уйның очы

солдатка барып төртелә, ни генә исәпләсә дә, ул эшнең ахыры солдатка барып бәрелә иде.

Әнисе: «Улым (углым), чәең суына», — димәсә, Садыйк бәлки шул хәлдә, шул уйда тагы әллә никадәр катып торган булыр иде. Бер кеше дә аның шул тынычлыгын бозмаса, ул бәлки шул авыр мәсьәләнең очына да чыккан булыр иде. Ләкин һәрвакытта да ул шул мәсьәләне уйлый башласа, ул үзенең солдатка китүен-китмәвен исәпли башласа, үзенең уе шул мәсьәләнең иң ямьсез вакытында гына чагында уе икенче якка борыла да күңелендә һәрвакытта ямьсез җәрәхәт калдыра. Бу юлы да шул булды. Ул үзенең китмәү ихтималын уйларга өлгерә дә алмады, энесе аны бүлде. Ул тиз генә ясаган чынаягын эчеп бетереп, дога кылып, өйдән чыкты. Әнисе: «Ерак китмә, әтиең кайткач та аш салам», — дип калды. Бу сүз тагы аның күңеленә үзенә бертөрле тәэсир итте. Әти кайтса, әни аш сала, солдатта әти дә ахшамнан кайтмас, әни дә аш салмас дип, тагы иске уйга кайтты, тагы балык башын чәйнәргә тотынды. Ул келәткә эләргә уйлап яңа йөгәнне кулына алды. Йөгән дә аның күңеленә аның солдатка китүен, солдатта мондый йөгәннәр булмавын хәтеренә китерде. Аның борынына яңа дегет исе керде. Бу ис тә аның шул фикерен беркетте. Ул йөгәнне келәттәге чөйгә элеп, капка төбенә чыгып, мичкә өстенә утырды. Элгәре бик озак кай төшеннән тотынып уйларга икәнлеген белмәенчә торганның соңында, тагы үзе тугрысында, тагы солдатка китү тугрысында уйларга тотынды. Менә сарык көтүе керде. Бөтен урамны шаулатып сарыклар кычкырыша башладылар. Өем-өем сарыклар Садыйкларга килә башладылар. Садыйк башын күтәреп карады. Алар да Садыйкка үзенең солдатка керүен, Садыйкның солдатка китүен хәтеренә китерде. Тагы бер-ике айдан сарык көтүе дә кермәс,сарыклар да кычкырмас кебек тоелды. Озак үтмәде, югары очтан әтисе дә күренде. Урам өсте өйнең ачык тәрәзәсеннән ит исе килә башлады. Әтисенең кайтуы, ит исенең борынына керүе дә Садыйкка һаман шул уйны уйлатты, һаман шул солдат мәсьәләсен күзе алдына китерде.

Аңарга, озакламаенча, этисенең намаздан кайтуы күренмәс кебек, озакламаенча, ит исе чыкмас кебек, озакламаенча, шул мичкәгә утырып торырга мөмкин булмас кебек тоелды. Әхмәди абзый да кайтты. Өйдә дә: «Аш өлгерде», — дигән тавыш ишетелде. Садыйк та, авырлыгыннан башын күтәрә алмаган кеше кебек, башын иеп кенә өйгә керде. Кич үтте.

## III

Аштан соң атларны карап Садыйк капка төбенә чыкканда аргы якта гармун тавышы берлә сузып-сузып көйли торган йыр тавышы, югары очтан моң гына сызгыру тавышы авылның икенче кырыенда анасыннан адашкан бәрән тавышы берлә әллә нинди бер малайның «әһү, әһү!» дип ат эзләү тавышы йокларга хәзерләнгән авылның тынычлыгын боза иде.

Садыйк акрын гына шул төрле төсле тавышлардан хасыйл булган авыл музыкасын тыңлый-тыңлый кая барганын уйламаенча югары очка менә башлады. Авыл йокламый иде, һәр өйдә кечкенә генә лампа яна, һәр тәрәзәдә чебен уты кебек кенә яктылык күренә иде, һәр өйдә аш эчү күренә, балалар тавышы ишетелә, һәр өйдә хатыннарның кызуланып-кызуланып аш хәзерләүләре яисә ашны җыештырулары күзгә ташлана иде. Болар һәммәсе дә озак аштан соң тамакларын туйдыргач йокларга, иртәгә тагы шундый 16 сәгатьлек эш көненә чыгарга хәзерләнәләр. Шул көнне исән-сәламәт каршы алыр өчен хәл җыярга ашыгалар иде. Кайсы өйдә түр башында карчыклар яисә картлар бер торып, бер ятып намаз укыйлар, кайсы өйдә балалар җык килеп сөт ашыйлар, кайсы өйдә хатыннар күтәреп-күтәреп кабартып түшәк җәяләр иде. Менә Садыйк Афзалларга җитте, аларда да шул эш, аларның да өйләрендә шул манзарә булса да, бүлмә тәрәзәсе башка өйләрнекеннән якты, башка өйләрнекеннән башка иде. Аларның бүлмә тәрәзәләре кызыл яулык берлә корылганга, җиделе лампа берлә яктыртылганга ул бөтен урамга икенче төс бирә иде. Садыйк тагы югары очка таба китте. Аның күзенә тагы кызыл яулык

корылган зур лампа берлә яктырылган тәрәзәләр очрый башлады.

Ул бу тәрәзәләрнең ник якты икәнлекене, ник кызыл яулык корылган икәнен бик яхшы белгәнгә, ул кызыл яулыклар, якты лампалар авыл кызларының авыл егетләренә үзләренең барлыкларын, үзләренең кызлыкларын, үзләренең күңелләренең сөяргә, сөешергә хәзерлекләрен күрсәтә торган галәмәт икәнен белгәнгә, бу кызыл утлар аңарга бер дә гаҗәп төсле күренмәде. Шул тәрәзәнең кызын уйлап, ул кызның үзләренең авылларының фәлән егет берлә андый-мондый бармак селкешүләрен, күз кысышуларын гына хәтеренә китерде. Менә Зөһрәнең тәрәзәсе төбенә җитте, аның тәрәзәсенә карарга тотынды, аның тәрәзәсе дә башка кызларныкы кебек яктыртылган, аның тәрәзәсе дә башка кызларныкы кебек пәрдә берлә капланган иде. Ләкин бу тәрәзә, бу яктылык, бу пәрдә Садыйкка әллә нинди башка тәрәзәләрдән, башка пәрдәләрдән, башка утлардан аерым кебек күренде. Бу тәрәзә, бу тәрәзәнең иясе, бу тәрәзәнең хуҗасы башка кызлар кебек шат, ачык түгел төсле күренде. Садыйкның күңеленә Зөһрәнең сөйгән егете Сафа килеп төште. Сафаның да Садыйк кебек быел солдатка каралуы, аның да Садыйк кебек тазалыгы, аның да солдатка китү ихтимал барлыгы, Зөһрәнең Гайниҗамал кебек үзенең сөйгәненнән аерылып калуы хәтеренә килде. Ул тагы тәрәзәгә карады, тәрәзәдәге утта тәрәзәне каплаган пәрдә дә, пәрдә артындагы кыз да шуны уйлаган кебек тоелды. Шуның кайгысыннан Зөһрә дә хәзер кәефсез кебек, шуның хәсрәтеннән лампа да караңгы кебек күренде. Садыйк: «Солдат, солдат! Сафа да китсә, мин дә китәм! Зөһрә дә кала, Гайниҗамал да кала», — дип кычкырып җибәрде. Ул шул минутта үзенең китүенә, Сафаның китүенә шулкадәр ышанды, аны бу вакытта нинди дәлил берлә дә шул уеннан кайтартырга мөмкин түгел иде. Ул үзенең китүенә ышанганга, көннәре актык көннәр дип беркетеп куйганга, үзенең шул кайгысын бүләр өчен, үзенең шул калган көннәрен мөмкин кадәр шатлыкта үткәрер өчен, Гайниҗамалны мөмкин кадәр күбрәк күрер өчен, аның берлә күбрәк сөйләшер өчен, аның берлә күбрәк сөешер өчен түбән очка таба борылды. Шул ара да булмады, аңар каршы тәрәзә яктысыннан бер шәүлә

селкенә башлады, шәүлә якынлаша башлады, менә шәүлә Мөхәммәдиләр тәрәзәсенең яктысы тугрысына җитте. Садыйк бу шәүләнең Сафа икәнен белеп, Сафаның ни уйлаганын белер өчен аның йөзенә карарга тотынды. Аңарга аның йөзе дә кайгылы төсле, аның башы да әллә нинди уйлы төсле күренде, тагы аны караңгылык каплады. Менә акыртын гына Сафаның сызгыруы ишетелә башлады. Зөһрәнең тәрәзәсендә пәрдә селкенде. Сафа да килеп җитте. Садыйк Сафага үзенең кем икәнлеген белдерер өчен тамак кырды. Сафа акыртын гына Садыйк янына килеп исәнләште. Садыйк Сафаның ни өчен килгәнлеген белгәнгә, аның ни өчен сызгырганын аңлаганга: «Бар, бар, юлыңда бул!» — дип, Сафаны озатмакчы булды. Сафа: «Тукта, ашыкма, мин хәзер чыгам, син Шаһиләр өй артында көт, аръякка чыгамыз, бүген Әхмәтҗаннарда кунак кызы бар», — дип, акыртын гына Зөһрәләргә таба сызгыра-сызгыра китте. Садыйк аны-моны уйламаенча гына, Шаһиләрнең өй артларына бармаенча, Зөһрәләрнең лапаслары буена баганага барып сөялде. Лапас эчендә чулпы чылтыравы ишетелә башлады. Менә тагы тавыш бетте. Бераздан соң тагы чылтырарга тотынды. Акыртын гына Зөһрәнең: «Монда!» — дигән тавышы ишетелде. Үзенең барлыгын белдермәс өчен Садыйк бер дә селкенмәенчә баскан урыныннан кузгалмады. Менә лапас эчендә Сафаның тавышы, чулпы тавышы, үбешү тавышы ишетелә башлады. Шактый гына вакыт үткәннең соңында Зөһрә тавышы, аның артыннан Сафаның пышылдавы ишетелә башлады. Садыйкның күңеленә үзенең Гайниҗамалы тагы төште. Ул Сафа берлә Зөһрә сөйләшүен түгел, барлыкларын да онытып, үзен, үзенең Гайниҗамалын уйларга тотынды.

Ул үзен, үзенең каялыгын онытты. Ул үзенең шул уена чумды, үзенең шул татлы уе берлә ләззәтләнә башлады. Лапас эчендәге: «Син китәрсең шул!» — дигән Зөһрәнең сүзе аңарга әллә нинди тәэсир итте. Ул элгәре шул сүзнең мәгънәсен аңламаган кебек, кая китү тугрысында сөйләнгәнне белмәгән кебек булды. Озак үтмәде, яшен ташы кебек аның күңеленә «солдатка!» дигән сүз килеп төште. «Әйе, солдатка китәрсең шул! Мин дә китәрмен шул!» — дип, шул уйны сузарга тотынды. Тагы лапастан: «Мин калырмын!»—дигән сүз

ишетелде. Аның уена тагы бер койрык ялганды. «Мин калырмын! Син китәрсең, син китәрсең, мин калырмын», — дигән сүзне авызында әвәләтә башлады. Тагы чулпы чылтыравы, тагы үбешү тавышы аны уятты. Озак үтмәде, Сафа да чыкты. Ул Шаһи өенә таба бара башлады. Садыйк үзенең каялыгын белдерер өчен сызгырды.

Садыйк Сафаны күрүе берлә, бер сүз дә әйтмәенчә: «Малай, китәбез бит!»—диде.

Сафа ни әйтергә белмәенчә, ачуланган тавыш берлә: «Син тилеме, түгелме? Бүген аны уйлыйлармы? Кая барсаң да бер кояш! Без генә китмәгән, ата-бабадан калган йола», — дип, сүзне борыр өчен: «Әхмәтҗаннарга кунак кызы килгән, әнә, ишетәмсең, безнекеләр ничек җырлыйлар»,—диде. Садыйк Сафаның ахыргы сүзләрен ишетмәгән кебек: «Ата-бабадан калган да, синең Зөһрәң кала! Минем...» — диде.

Сафа ачуланып: «Син бүген тирес торган ахырысы! Әллә Зөһрә урынына Зөһрә беткәндерме!» — диде. Садыйк каршы бер җавап та бирмәенчә үз уена чумды. Озакламады, гармун уйный торган иптәшләре янына килеп җиттеләр. Садыйклар барып җиткәч, гармунчы җиңел көй уйный башлады. Бу көй Садыйкның уен борды. Ул үзенең ямьсез уйларын онытып, иптәшләре берлә көлешергә, сөйләшергә, җырлашырга тотынды. Озак үтмәде, салышып, чәй эчәргә уйладыла.Һәм дә, тиз генә салышып бал чәкчәге, алма, күмәч алырга җибәрделәр. Үзләре барысы да Гарифә әбигә кереп самавыр куйдырдылар. Чәй янында егетләр авылның бөтен кызы хакында, кунак кызы хакында әллә нинди сүзләр сөйләделәр, әллә никадәр көлделәр, берсеннән берсе арттырыр өчен, үзләре әллә никадәр кыз күргән итеп күрсәтер өчен, үзләренең кызлар алдында бик кадерлелекләрен исбат итәр өчен әллә никадәр ялганладылар. Ишеткән бер хикәяне үзләре күргән, үзләре кылган дип сөйләделәр.

Сафа да үзе тугрысында сөйләде, ул да үзен әллә кемнәр сөйгәнен сөйләде, ул да алдады, аны да тыңладылар. Кыскасы гына, монда бөтен кеше

алдый, бөтен кеше сөйләүченең алдавын белә, бөтен кеше ләм-мим дип сүз кайтармый иде. Болар арасында кызлар сөешү тугрысында алдау шулкадәр җәелгән иде, бу алдау боларга каннарына шулкадәр сеңгән иде, алар шул алдаудан башка мәҗлеснең ямен тапмыйлар, тормышның ләззәтен белмиләр иде.

Садыйк боларның алдауларын тыңлады. Боларның әллә ничәшәр кат ишеткән хикәятләрен тагы ишетте. Ул да алар кебек ышанган кебек бер сүз әйтмәде. Ул да алар кебек көлде. Ул да алар кебек ялганлады. Бу ялган аңарга да үзенең ямьсез уйларын онытырга, үзен-үзе алдарга, үзен-үзе кәефле кебек иттереп уйлатырга сәбәп булды. Озак үтмәде, Садыйк күкрәгендәге бүләген исенә төшереп, Гайниҗамал янына барыр өчен, ялган хәйлә табып, чыгып китте. Озакламаенча, Гайниҗамалның тәрәзәсе төбенә килеп тә җитте. Аның да тәрәзәсе башка кызларныкы кебек пәрдә корылган, башка кызларныкы кебек яктыртылган иде. Ул тәрәзә янына килеп карарга тотынды. Пәрдә ашасыннан Гайниҗамал күренмәсә дә, пәрдәдәге аның шәүләсе ап-ачык күренә иде. Аның кулының селкенүе, аның йөзе, авызы, хасыйле, һәммә әгъзасы беленә иде. Садыйк бу әгъзаларның барысын да бик күптәннән бирле таныганга, аның Гайниҗамал нишләгәндә авызы нинди булуын, күзе ни төсле булуын белгәнгә, ул пәрдә аша күренә торган Гайниҗамалны бик озак карап торды. Ул Гайниҗамалның һәр хәрәкәтеннән, аның һәр селкенүеннән әллә никадәр ләззәт алды. Карап туйганның соңында ул акыртын гына тәрәзәне чиертте. Менә пәрдә селкенде, тәрәзәдән Гайниҗамал күренде. Ул акыртын гына башын селкетте. Садыйк аның ни әйткәнен аңлап, лапас астына керер өчен Гайниҗамалларның күршеләр йорты аша аларның артларына чыкты. Сарыклар курыкмасын өчен акыртын гына басып лапас астына керде. Өй ишеге ачыла башлады. Садыйкның йөрәге леп-леп сикерә башлады. Озак үтмәде, комган күтәреп Гайниҗамал чыкты. Ул акрын гына лапаска таба килә башлады. Садыйк акрын гына сызгырды. Озакламады, Гайниҗамал Садыйкның кочагына керде. Алар тагы бик озак сөйләштеләр. Тагы бик озак сөештеләр. Тагы берсеннән берсе аерылмаска булып вәгъдәләр кылыштылар.

Тагы үбешеп аерылыштылар.

Тагы Садыйк өенә кайтып үзенең лапас астына аскан чанасына менеп ятты, тагы иртә торып эшкә тотынды, тагы кич берлә йөрергә чыкты, тагы Гайниҗамал янына барды, тагы, атна саен иген берлә шәһәргә барып, Гайниҗамалга бүләк алып кайтты. Шулай итеп көннәр үтте. Набор җитте.

## IV

Набор башланды. Садыйклар да бөтен авыл егетләре берлә шәһәргә киттеләр. Бөтен авыл моң, күңелсез төскә керде. Урамның ул очында да, бу очында да ишетелә торган егетләрнең йыр тавышлары, аларның бертуктамый гөрли торган гармун тавышлары ишетелми башлады. Тәрәзәләрдәге кызыл яулыклар да тоныграк, аларның артындагы кызлар да моңрак кебек күренә башлады. Һәр өйдә карчыклар, картлар бик тырышып әллә нинди хуҗаларга догалыклар укый башладылар, әллә нинди изгеләргә угылын калдыру яисә фәлән абыстайның киявен калдыру, йә фәлән кызның сөйгәнен калдыру тугрысында догалар ычкындыра башладылар.

Мулла абзый да һәр намаздан соң әле аның өчен, әле моның өчен дога кыла башлады. Һәр өйнең йә угылы, йә кияве, йә дусты кергәнгә бөтен авыл өмет берлә өметсезлек арасында яши башлады. Төшче әбиләрнең курслары күтәрелде. Муллаларның төш тәгъбирләре өйдән өйгә йөри башлады. Бөтен авыл шәһәрдән хәбәр көтә башлады. Бөтен авыл шул уй, шул фикер берлә генә яши башлады. Әүвәлге көнне берни булмаганны, икенче көнне тикшерү (кличка) булганны, өченче көнне шобага алуны ишеттеләр. Һәркемнең авызында шобага Сәфәрләре әвәләнә башлады. Барысы да шобага җитәрлекме, түгелме, шабаш (шатбаш)ка калырлыкмы, түгелмелеген уйлый башладылар. Садыйкның да шобагасы беленде, аның шабашка калу ихтималы барлыгы бөтен авылда сөйләнә башлады.

Гайниҗамал бөтен авылның карчыкларына төшлекләр, ниятләр таратты.

Әллә никадәр хуҗаларга әллә ничәшәр күкрәкләр, сөлгеләр, салфетлар нәзер итте. Каралу башланды. Иң әүвәл һич уйламаган, авылда таз дип калырга хөкем ителгән бер егет алынды. Аның артыннан тагы бер, тагы бер алынды. Бу өч солдат авылның кайсы өйләрендә өметне өметсезлеккә әйләндерде. Күп өйләрдә күз яшьләре түктерә башлады. Икенче көнне бөтен авыл утлы күмер өстенә баскан кеше кебек тагы яңа алулар, яңа калуларны көтә башлады, шәһәрдән кайткан бер кешене чормап, следователь кебек сораша башлады. Кичкә таба бу көтү тагы куәтләнде. Күп аналар шәһәр юлына чыгып кайтучыларны көтә башлады. Зөһрә дә, Гайниҗамал да, авылның башка кызлары да бу көнне бик авыр үткәрделәр. Кич берлә тагы дүрт кешенең алынуы, алар арасында Сафаның булуы бу кайгының тагы күбрәк өйгә җәелүенә сәбәп булды. Төнлә берлә соң гына шәһәрдән Закир да кайтты. Ул эниләренә, якын карендәшләренә Садыйкның бүген каралмавын, Садыйкның иртәгә соң гына каралуын, аның шабашка калуы бик ихтималлыгы хәбәрен китерде. Садыйкның анасы, Гайниҗамал тагы яңа нәзерләр әйттеләр.

Тагы яңа өметләр берлә йокларга яттылар. Икенче көнне үткәрү Гайниҗамал өчен бик авыр булды. Аңарга үзенең бу кайгысын кайгыртудан битәр, ул кайгыны кайгыртмаган төсле булып күренү кайгыдан да авыр тоелды. Ул шуның өчен әллә никадәр куәт сарыф кылырга мәҗбүр булды. Менә кич тә булды. Шәһәрдән бер хәбәр дә алынмады. Гайниҗамал урынында утырып тора алмый башлады. Ул үзенең аналарыннан яшерер өчен, үзенең дус кызына кич утырырга китте. Анда да йөрәгенә урын таба алмады. Аңарга минут сәгать кебек, сәгать ел кебек озак үтә башлады. Менә кыңгырау тавышы ишетелде. Ул әллә никадәр вәгъдәләр кылып, дустының сеңелесен белешергә җибәрде. Күңеленнән тагы нәзерләрен зурайтты. Актык минут та җитте! Гайниҗамал әйтеп бетерә алмаслык бер сабырсызлык берлә хәбәр көтә башлады, кыз кайтты. Ишектән керер-кермәс: «Садыйк абзый киткән!» — диде. Бу сүз Гайниҗамалны яшен суккан кебек ясады. Ул үзен-үзе тыя алмаенча, үзенең хиссиятен яшерә алмаенча, үкереп-үкереп еларга тотынды. Бик озак елаганнан соң Гайниҗамалда әллә нинди бер куәт берлә Садыйкны

күрәсе теләү хисе уянды. Ул үзенең бу хисен сакларга теләсә дә, бу теләүне булдыруны бүген үк, хәзер үк нинди авыр идекен белсә дә, җалынып-җалварып, тагы теге кызны Садыйкка җибәрде. Озак үтмәде, кыз да кайтты. Аннан соң тәрәзә дә шылтырады. Бераздан Гайниҗамал Садыйкның кочагына атылды. Ул: «Киттеңмени?», — дигән сүздән башканы әйтмәенчә, Садыйкның битен кайнар яшь берлә юарга тотынды. Бик озак уйлаганнан соң, бик озак суырып-суырып үпкәннән соң, әллә ничәшәр мәртәбә бер-берсенә көтешү вәгъдәләре кылышканнан соң, Гайниҗамал бераз басылып өйгә керде. Ул хәзер үзенең шул кайгысы берлә, үзенең шул бәхетсезлеге берлә килешә башлады. Садыйк Гайниҗамалның кочагында тагы үзенең киләчәк ямьсез тормышын баштанаяк уйлады. Карт солдатлардан ишеткән дөрест-ялган хикәяләрне һәммәсенә дә бер күз берлә карап, ни булса да сабыр итәргә, ни күрсә дә шул Гайниҗамал өчен онытырга, һәрвакытта Гайниҗамал өмете берлә шатланырга уйлап куйды. Озак үтмәде, бөтен киткәннәрне тагы шәһәргә җыйдылар. Аларның һәммәсенә кая китүләрен белдерделәр. Садыйк үзенең Лодзяга китүен белеп кайтты. Тагы авылның урамнары йыр берлә, гармун берлә яңгырарга тотынды. Ләкин бу йырлар элгәреге кебек шатлыклы, өметле йырлар булмаенча, кайгылы моңлы, аерылу йырлары иде. Элгәреге йырлар пәрдә артындагы кызларда шатлык хисе уяндырган кебек, бу йырлар аларда кайгы, өметсезлек хисе уяндыра иде. Бик күп өйләр кайгы төсен алды. Бик күп аналар иртәдән кичкә кадәр күзләреннән яшь агыза башлады. Әлеге төшче карчыклар угылларының сәламәт кайтуы өчен, бәхете берлә илгә кайтуы өчен тагы догалар кыла башладылар. Ниятләр укый башладылар. Китәр көн дә җитте. Садыйк кич берлә Гайниҗамал янына барып аның берлә саубуллашты, аның берлә янә ныклап вәгъдәләште, аный, берлә көтешергә, бер-берсеннән башкага кияүгә чыкмаска сүз алышып, бәхилләшеп кайтты. Озак үтмәде, Садыйк иптәшләре берлә билгеләнгән шәһәренә китте.

**V**

Садыйк аркасына күлмәк-ыштан, башка әйберләрне тутырган капчыкны асып әллә никадәр үзе кебек капчыклар аскан рус, чуаш, татар егетләре берлә юлга чыкты. Әтиләре бик озакка кадәр озата килделәр. Бик озын иттереп, әллә ниләр сөйләшмәкче булдылар, ләкин берсе дә сөйләргә сүз таба алмаганга, бер-берсенә карашып кына бардылар. Менә аталарына кайтырга вакыт җитте. Әтисе: «Угылым, хуш!» —д иде дә еларга тотынды. Садыйк никадәр нык төсле күренергә теләсә дә, ул да чыдый алмады. Аның да күзеннән яшьләр мөлдери башлады. Әтисе тагы бераз елаганнан соң кесәсеннән озын баулы янчыгын чыгарды да бакыр акчалар арасыннан актарып-актарып бер өчлек кәгазь чыгарып: «Мә, угылым, тагы берәр җиреңә ярар, акча кирәк булса, хат яз. Анда больницага-фәләнгә керә алмассың, майларлык юл булмаса», — диде дә кызу-кызу акчасын кесәсенә тыгып куйды. Садыйк әтисенең сүзләренә бер җавап та кайтармаенча, үзенең башын катырыр өчен ап-ак кар берлә томаланган сахрага карарга тотынды. Аның күңеленә тагы авыллары, авылларының урамнары, авылларының кызлары, Гайниҗамал, әнисе, сеңелләре килә башлады. Алар барысы да моны озаталар, алар барысы да эч күңелләреннән кайгырталар, алар барысы да әнисе берлә бергә еглашалар кебек күренде. Аның күз алдына еглаудан күзләре кызарган әнисе, сеңелләре, Гайниҗамал күренгән кебек булды. Аның куллары аларның кайнар кулларын кысып күрешкән кебек булды. Аның авызы Гайниҗамалның авызын үпкән кебек булды, аның бите Гайниҗамалның кайнар яше ага торган битләренә тигән кебек булды. Ул үзен-үзе тыя алмады, еларга тотынды. Әтисе, аның янындагы энесе Закир да еларга тотындылар. Еглап-еглап очына чыга алмаганның соңында Садыйкның атасы атны борып: «Угылым, хуш, тәүфыйк, бәхетең берлә кайт», — дип, Садыйкка карамаенча гына кулын сузды. Садыйк: «Хуш, эти!.. Әнигә сәлам әйт! Гайшәгә сәлам (сеңеле) әйт. Гайниҗамалны... җибәрмәңез», — дияргә өлгермәде: «Ярар, ярар, угылым», — дип, атасы Садыйкның әйтеп бетерә алмаган уен тутырды. Закир да абзыйсы берлә күреште, алар акрын гына атларына утырдылар да киттеләр. Садыйк яңадан күз яшьләрен яңартмас өчен бик озак артына карамаенча барды. Ул никадәр артына карарга теләсә дә һәр минутта,

һәр секундта да артында әллә нинди бик кадерле нәрсәсе калган кебек хис итсә дә, артында гомеренең иң матур вакытлары, балалыклары, егетлекләре калганлыгын, аларның мәңгелеккә кайтмаска калганын белсә дә, ул хисеннән котылыр өчен, ул уйдан качар өчен ул күзен һаман алга юнәлтте. Ул үзенең авылың, үзенең балалык вакытларын, үзенең егетлеген, үзенең Гайниҗамалын онытыр өчен иптәшләре берлә сөйләшергә теләде. Ләкин алар да үзләренең артларында үзләренең авылларын, аталарын, аналарын, хатыннарын, сөйгәннәрен калдыргагнга, аларны да шул аерылышу кайгысы, шул үткән матур көннәр хәсрәте кергәнгә, алар да Садыйкның күңелен ача алмадылар, алар да моның кебек сөйләшмәскә, сөйләшсә, үткән тормышны хәтергә кертмәскә, йокларга ята  торган аерылу кайгыларын уятмаска тырышкан кебек, сүз арасында ул мәсьәләнең яныннан үттеләр.

Менә  әллә нигә атлар туктады. Садыйк озын  обозның бер башыннан икенче башына таба карый башлады. Алда аларны алып бара торган өч солдатның әллә нигә туктап бергә сөйләшүләре, тәмәке кабызуларыннан башка берни күрмәде. Артка карады. Анда тагы бер солдатның еглап-еглап аерылышу манзарәсе күзенә ташланды. Ул күптән түгел генә үзенең дә, шул хәлдән үткәнен хәтеренә төшереп, артта калган әтиләрен эзләргә тотынды. Әтиләре әллә кая ерак киткәннәр. Әнә үргә таба менәләр... Әнә чабалар. Алар шул хәсрәттән аерылыр өчен, шул кайгы берлә аларның арасындагы җирне ерагайтыр өчен атны кыйнап-кыйнап чабалар. Садыйк атны кызганды, ат мескен бик өшәнер инде, йөрүдән туктаганы юк дип уйларга тотынды. Аттан соң Садыйкның уе әтисенә, әнисенә, аннары Гайниҗамалга барып җитте. Бу ноктадан уза алмаенча шунда катты. Ул хәзер үзенең Гайниҗамалдан чынлап аерылганын, Гайниҗамалны дүрт елсыз күрүе ихтималы юклыгын, Гайниҗамалны дүрт елсыз үбү-кочу ихтималы юклыгын, бәлки бөтен гомергә аның югалуын хәтеренә китерде. Ул үзенең ничек бу солдатка китүен, ник бер юл эзләмәвен, ник бүтәннәр кебек колагын тишмәвен, аягын бозмавын уйлый башлады. Ул вакытта ул калыр иде. Ул хәзерге вакытта Гайниҗамал берлә бергә булыр иде. Ул вакытта ул озакламаенча Гайниҗамал берлә туй итәр иде.

Ул вакытта ул Гайниҗамал берлә кияүле-бикәчле булып йөрер иде. Ул вакытта хәзерге кебек күз яшен буып тотмас иде. Ул вакытта ул бу озын кешеләре күз алдына килә башлады. Аларның кайсысының авызы чалышлыгы, кайсысының аягы аксаклыгы, кайсысының күкрәге череклеге хәтеренә төшеп, үзенең тап-тазалыгы, үзенең шәм кебек турылыгы, яшь имән кебек ныклыгы хәтеренә төшеп, бозмавына шатланды. Ул ихтыярсыз: «Мин бозмадым, мин киттем, мин исән кайтырмын, алар гомергә авыру булырга да өлгерә алмады, аларның авылларының бай малаеның моңардан да таза булса да калуы, аның соңында боларның күршеләренең угылының бозмаенча калуы хәтеренә килде. Аларның хәзер өйдәлекләре, аларның хәзер үзләренең сөйгән кызлары берлә күрешеп йөрүләре, өйләнүләре күз алдына килде. Ул: «Ник соң мин китәм? Ник соң мин солдатка барам? Ни өчен?» — дип уйларга тотынды. Аның башында боларга берсенә дә җавап булмаганга, ул, ата-бабадан калган йола инде, дип җавап бирде. Тагы күңеленә: «Ник болай булган! Менә ат чабыштыру йола булган, менә казлар йолкырга кызлар йөри, кызлар янына егетләрнең керүе йола булган. Бу да шундый йоламы? Сабан туенда иренә, хатынына, егетенә, кызына шатлык була. Сабан туй өчен беркем дә үзенең туган йортыннан, үзенең сөйгән кызыннан, сөйгән егетеннән аерылмый. Кызлар янына егетләр керү дә аларның бармак санаш, йөзек яшереш уеннарында да беркемгә дә бертөрле дә хәсрәт-кайгы булмый. Юк, бу солдатка китү андый гына йола түгел. Бу — башка», — дип уйлап куйды. Ләкин ник башкалыгы, ник солдатка моның китүе, ник солдатка бу кадәр яшь егетләрнең китүе, ник аларның ул колакларга да кермәгән әллә нинди Лодзя Лавес кебек шәһәрләргә җибәрелүе моңарга һаман шул хәл кылынмаган көенчә сөаль булып калды. Ул үзләренең авылларындагы иске солдатларның шул хакта сөйләүләрен, башка картларның сөйләүләрен уйларга тотынды, аннан да бер җавап та таба алмады. Ул ничек тә җавап таба алмагач, язмыш шулайдыр дип, эшне бетермәкче булды. Ләкин аның башына тагы: «Ник язмыш алай?» — дигән сөаль килеп, тагы җавап сорый башлады. Ул сөальгә җавап бирергә үзенең көче юклыгын белгәнгә обозның уртасында йырлаучы егетләр янына

барып йырларга кушылды. Әүвәле үзенең күңелендәге тавышны басар өчен, аның туктамаенча бирә торган сөальләрен ишетмәс өчен авызын бик тутырып йырларга тотынды. Йырлый-йырлый фикерләр башкага әйләнде. Баягы сөальләр башка килми башлады. Арадан берсе киләчәктә солдат булып торуны бик матур буяулар берлә бизәкләп күрсәтеп сөйли башлады. Садыйк та үзен солдат иттереп үк хис итә башлады. Озакламады, тимер юл стансәсенә барып җиттеләр, һәм тимер юл берлә Лодзяга таба киттеләр.

## VI

Лодзяда боларны шәһәрнең кырыенда гына бик озын, бик күп тәрәзәле ак пулатка илтеп, һәммәсен берәм-берәм исемнәре, фамилияләре берлә кычкырып казармага керттеләр. Әйберләрен карарга, күлмәк-ыштаннарын санарга,китапларын тикшерергә тотындылар. Бик озак шул эшләр берлә боларны борчыганнан соң, иске солдатлар, җилкәсенә җиңенә тасма теккән унтер эфисәрләр боларны урынлаштырдылар. Озак үтмәде, аш вакыты җитте. Звонок булды. Солдатлар берәм-берәм кухняда аш алырга чыга башладылар. Садыйкка бу озын, очы күренми торган өй, бу исәпсез тезелгән караватлар, бу бертуктамаенча ашханәдән аш күтәреп керә торган соры шинельләр кигән, кара казакиләр кигән яшь егетләр, бу, кәбестә исе бөтенләй ят булганга, бу өй, бу кешеләр, бу ашлар моның элгәреге тормышына аз гына да охшамаганга, ул вакыт-вакыт үзенең кайдалыгын онытып җибәрә иде. Менә аларга да ашлар китерелде, аларга да зур кашыклар бирелде, менә алар да ашый башладылар. Бөтен казармада тагы төче ис күтәрелде. Садыйк мондый рус ашын ашаганы юкка, рус ашын күңеленнән генә бик тәмсез була дип хөкем итеп куйганга, ашамаска да уйлаган иде. Ләкин озак торып ашыйсы килүе аны җиңде. Ул чирканып кына, җирәнеп кенә ашарга тотынды. Аш артыннан ботка да ашалды. Аштан соң әллә нинди бер укалырак солдат кереп, боларны берәм-берәм чакырып, иске шинельләр, иске казакиләр, иске итекләр бирә башлады. Садыйк та җиң төбе әллә ничә җирдән ямалган кара казаки, иләк кебек үтә

күренә торган соры шинель, бик ямьсез форма берлә тегелгән тупас итек алды. Аның соңында аларны барысын да мунчага җибәрделәр. Әллә никадәр кайнар, салкын су краннары берлә тулган, умарта корты кебек ялан өст кешеләр кайный торган, һәр почмагыннан кайнар су күтәрелә торган, идәннән шылтырап сабынлы йылы су ага торган бу мунчада үзен ят төсле күрде. Ул бу кадәре ялан өст кешеләр арасында юынырга мунчага керергә бераз җирәнә, бераз ояла. Ул, өйдә вакытта булса, яисә хәзер дә керү-кермәү аның ихтыярында булса, ул шөбһәсез хәзер дә кермәс иде. Ләкин аның хәзер солдат булуы, солдатның кушкан бер эшне тотарга тиеш булуы аның күңеленә, әлбәттә, кермәү уен китерми дә иде. Ул юынып чыккач, тартып-төртеп казакисен, чалбарын төймәләде. Итеген нык итеп киде. Ул үзенең солдат киемендә нинди идекен күрер өчен көзгегә карады. Аңарга ул хәзер тәмам бөтенләй башка кеше кебек күренде. Бер җирендә аның өстендәге аннан җыерылган, моннан җыерылган казаки, әллә ничә төшеннән кара җеп берлә тегелгән иске чалбар аны бөтенләй үзгәрткән иде. Ул үзенә үзе исе китте, ул үзен үзе көчкә таныды. Аңарга бу кием берлә әти-әнисе, Гайниҗамалы танымас кебек була иде. Ул шул уйларны уйлап көзге янында катып тора башлады. Бер, карт солдат, «Әй, новобранец! Нәрсә каттың? Төймәләреңне яхшы төймәлә», — диде. Садыйк уянган кебек булып, калган төймәләрен дә төймәләде. Ул шуннан соң үзен элгәреге Садыйк түгел кебек, элгәреге Садыйк әнә шул иске чалбар, иске казаки астында калды кебек хис итте. Кайтырга дип шинельне кигәч, аның ул хисе тагы куәтләнде. Кич берлә аларның занятиеләре башланды. Аларның әфисәрләре кем идекен, полковниклары кем идекен өйрәтә башладылар. Икенче көнне боларны бишәр-бишәргә бүлеп, карт солдатларга өйрәтергә бирделәр. Садыйк бик тырышып өйрәнә башлады. Карт солдатлар боларга мужик дип караганга, монда авылны сөйләү, авылны мактау начар солдатлыктан хисап ителгәнгә, Садыйк яхшы солдат булыр өчен авыл тугрысында сөйләми, Гайниҗамалны уйламый башлады. Ул бик тырышып өйрәнә башлады. Өч ай эчендә Садыйк әфисәрләр, полковниклар, генераллар, тагы шундый әллә кемнәрнең эполетлары ни төслелеген, аларның кайсысы

«Его благарудия», кайсысы «Высакаблагарудия» икәнлеген өйрәнде. Уенны да тәмам өйрәнеп җитте. Һәр көнне иртә берлә әллә ничә карт солдатның итеген чистартып, аларның да мәхәббәтләрен җәлеп кылды. Ләкин күңелендәге теге сөаленә монда да җавап таба алмады. Ник солдатка алалар? Ник бу кадәр зур казармаларга шул яшь егетләрне җыеп, соры шинельләр кигезеп, эшти ашлаталар? Ник эфи-сәрләрнең укаларын ниндилеген өйрәтәләр? Боларның эфисәрләре боларга: «Сез хәзер инде солдат булдыңыз, солдат булу бик зур эш! Солдатның честен саклау — сезнең вазифаңыз, сезне падишаһлыкны дошманнан саклар өчен, падишаһка хезмәт итәр өчен монда китерделәр», — дисә дә, Садыйк: «Нинди дошман? Ник дошман? Сугыш бармы икәнни?» — дип тә уйлап караса да, тагы элгәреге бикләнгән рамнан үтә алмады. Ул хәзер аны-моны уйламаенча, ник солдат булганын исәпләмәенчә яхшы солдат булырга, эфисәрләрдән «спасиба» алырга уйлап куйды. Шул фикер берлән ул беркемгә дә карышмаенча хезмәт итә башлады. Вакыйга озак үтмәде, Садыйк дядькалар, унтер эфисәрләр алдында яхшы солдат исемен ала башлады.

## VII

Лодзяга килгәннән алты-җиде ай үткәннән соң Садыйк танымаслык дәрәҗәсенә килгән иде. Ул хәзер шактый гына русча сөйли белүдән, солдат уенына тәмам өйрәнеп җитүдән, чиннар-фәләннәрнең исемнәрен, солдатларның кыланышларын тәмам ядка алудан башка эченнән дә үзгәргән иде. Ул хәзер авылдагы кыш көне азбар көри торган, җәй буе кырда эшли торган, эшләү берлә ашаудан бүтәнне белми торган үзенең авылы берлә күрше шәһәрне генә күрә торган, өстеннән һәрвакыт тирес берлә тир исе чыга торган мужик егете түгел иде. Ул хәзер әллә ничә шәһәр күргән, әллә ничә шәһәр күргән кешеләрне күргән солдат Садыйк Әхмәдич иде. Ул хәзер үзенең авылын исенә төшергәндә, үзенең иптәш егетләрен хәтеренә китергәндә дә һәрвакыт аларга түбән күз берлә карап: «Мужик инде, мужик!» — дип кенә

куя иде, ул үзенең хәзер солдатка китүенә кайгырту түгел, хәтта шатлана иде. Аңарга хәзер авылның кечкенә өйләре бу зур казармага чагыштырганда бик кечкенә, бик ямьсез булган кебек, авылдагы күбесе бәрәңгедән гыйбарәт булган аш та бик тәмсез, андагы тунлы иптәшләр дә шоп-шома булган солдатларга караганда бик тупас кебек күренә иде. Ул хәзер карт солдат дәрәҗәсенә кергәнгә, ул һәрвакыт кесәсендә акча тота алырлык байлыгы булганга, ул хәзер начальства каршында да «Садыйк Әхмәдич — маладис!» булганга бәйрәм көннәрне бәйрәмчә үткәреп, якташ солдатларына кунакка барып, гостиницаларга керә алганга, аның тормышы хәзер бик җиңел үтә, вакыты бик күңелле уза иде. Аның хәзер тормышының тулмаган җире булса, ул да монда Гайниҗамалның булмавы, әллә нидә генә бер булса да этиләрен-әниләрен күрә алмавы иде. Ул өеннән бик еш-еш хат алса да, ул һәр хатта авылның бөтен кодагый-әбиләр, кодача абыстайлары, ил күршеләре, мәсҗед картлары, мәхәллә имамлрыннан бик сагынып, бик саргаеп, бер күрергә зар вә интизар булып сәламнәр укыса да, ул үзенең Гайниҗамалыннан да төрле каралар берлә бизәкләп бетергән, кырыена борып-борып бәетләр язган исле май сөртелгән хатлар алса да, аның күңеле алар берлә генә канәгатьләнми, аның дәрте аның берлә генә кайтмый иде. Ул күп вакытта шәһәрдән-фәләннән йөреп кайтып йокларга яткач, бик озак уйлап ята. Үзенең Гайниҗамалының ни эшләгәнен белергә тырыша, үзенең аның берлә булган бар вакыйгаларын башыннан алып очына кадәр күңеленнән кичерә, Гайниҗамалның күрешкәндә елаганнарын күз алдына китерә иде. Аңарга хәзер дә Гайниҗамал кайгыра, аның өчен Гайниҗамал еглый кебек күренә иде. Шуның артыннан Гайниҗамалның вәгъдәсен бозуы, Гайниҗамалның бүтән егет берлә йөри башлавы, Гайниҗамалның кияүгә чыгуы, Гайниҗамал берлә аерылышулары, бу киткән көнне азбарда үбешүләре актык үбешү булуы хәтеренә килә иде. Аңарга тагы Гайниҗамал еглаган кебек, Гайниҗамал моның берлә бәхилләшкән кебек күренә иде. Шул эшнең иртәгесен үк ул бик озын иттереп, тирәләренә тагы матур бәетләр язып, Гайниҗамалга яза, үзенең күңеле шикләнгәнен бәян кыла, Гайниҗамалга вәгъдәсен бозмаска җалына, җалвара

иде. Озак үтми, тагы Гайниҗамалдан хат ала иде. Тагы күңеле урынына утыра иде. Тагы Гайниҗамалга үзенең аны сагынуын, аны сөюен язарга тотына. Тагы, үзе мәдрәсәдә өйрәнгән шаблон буенча «җанымның җаны, бәгыремнең каны» берлә хатны тутырып, сачәкләр ябыштырып җибәрә иде. Көндезләрен уйнау, кайвакытларда каравылга бару, еш-еш кына хат алу, сөальләргә җавап язудан башка Садыйкның башка эше юк иде. Монда кайгырырга, шатланырга эш булмаганга, ул артык кайгырмый, артык шатланмый, ашап-эчеп, юынып, итек чистартып, сирәк-сирәк шәһәргә чыгып гомерен уздыра, вакытын үткәрә иде. Казармада төрле солдат булса да, кайсы солдатлар бик күп книгалар укысалар да, Садыйк бер дә русча укый белмәгәнгә, икенчедән, укудан ләззәт алмаганга, ул бернәрсә дә укымый, бернәрсә хакында мәгълүматын арттырмый иде. Шулай булса да аның башына хәзер авылда вакытта булмаган яңа мәгълүматлар кергәләгән иде. Ул да шундый үзенең яхшы солдатлыгын күрсәтергә җай килүен, внутренни вракны «һәң» генә иттерергә тугры килүен эченнән көтә дә иде. Ул начальства алдында тагы «маладис» булыр өчен иптәшләр арасында сөйләнергә, новобранецлар алдында мактанырга эш булсын өчен шул эшнең тизрәк булуын көтә иде. Ләкин шәһәрдә тынычлык булганга, эшчеләр арасында андый-мондый тавыш-тын булмаганга, һаман Садыйкка үзенең уены мәйданга чыгарырга җай килмәгәнгә һаман аның уе уй гына булып калып, ул һаман шундый сүзләрне сөйләгәндә тыңлаучы гына булып торырга мәҗбүр булганга, аның күңелен дә әллә нинди бер нарасыйлык хисе ашый, шул хис аңарга тынычланып йокларга ирек бирми иде. Шул фикерне аның мәйданга чыгара алмавына бер сәбәп, аныңча, тагы шул ук еврейлар, поляклар сәбәп булганга, аның аларга дошманлыгы артканнан арта бара иде. Аның күңелендә шуларның барысы өчен дә үч алу уе береккәннән берегә бара иде.

## VIII

Тагы бер ел үтте. Садыйк тәмам карт солдат булып, казарманың тәмам

правалы гражданы булды. Ул да башка солдатлар кебек итеген үзе чистартмый башлады. Ул да башка солдатлар кебек яңа солдатларга мужикка караган күз берлә карый башлады. Ул хәзер тәмам казарма кешесе булды. Ул хәзер чын солдат булды. Аның тышкы каты гына түгел, бөтен эче башкарды. Ул хәзер үзенә бер төрле караш ясады. «Яхшы», «начар» дигән сүз, «ярый», «ярамый», «матур», «ямьсез» дигән сүз аның кашында элгәреге мәгънәсен югалтты. Аныңча, хәзер начальства яраткан эш нинди генә булса да яхшы эш иде. Нинди генә булса да аны эшләргә ярый иде. Ул һәрнәрсәгә шул «начальства» дигән күзлек аша караганда ул һәр мәсьәләне бик җиңел хәл кыла, һичбер мәсьәлә хакында баш ваттырып уйлап та тормый иде. Шуның өчен ул үзенең яңа солдат вакытында: «Ник солдатка алалар? Солдат ник кирәк?» — дигән сөаленә дә хәзер көлеп кенә: «Начальства шулай куша», — дип җавап бирә иде. Һәм дә үзеннән яшь солдатларга да шул фикерне күңелләренә урнаштырырга тырыша иде. Ул һәр мәсьәләне, хәл кылырга юлын тапканга, һичбер мәсьәлә хәзер аны сөаль булып башын ватып тора алмаганга, ул безнең мәдрәсәләрдә «Исагуҗи» укый башлап, инсанның маһияте — хәйване натыйк, ишәк(неке) — хәйване саһил, фәләннеке фәлән дип, һәр нәрсәгә җавап тапкан шәкерт кебек, үзеннән үзе бик риза, үзенең кыйммәтене бик белә иде. Аныңча, һәр начарлыкның нигезе начальствага каршы тору, һәр яхшылыкның башы начальстваның сүзен тоту иде. Шуның өчен солдаттан качкан иптәшләренә бик яман күз берлә караган кебек, начальстваның сүзен ноктасы берлә тутырмаган солдатларга да шул күз берлә карый иде. Нинди суык көнне, нинди ямьсез җил-буранлы төнне каравылга барырга тугры килмәсен, ул һәммәсен ноктасы берлә урынына китерә иде. Ул шулкадәр һәрнәрсәгә үзенең начальства күзе берлә карарга өйрәнгән иде, әгәр аңарга үзенең иң якын иптәшен атарга начальства кушса, ул аны ләм-мим димәенчә атачак иде. Ул казармадагы кайсы солдатларның авыл хәлләрен сөйләүләрен барысын да начальствага тирес эш дип иман китергәнгә, андый сүзләрне сөйләүче...

Садыйкның начальства әмере берлә йөрмәгән бер эше булса — ул да

Гайниҗамалны сөюе, аның берлә хатлар язышуы иде. Ул, ничектер бу мәсьәләне үзенең мантыйкыйда аерып йөрткәнгә, аның хакында бервакытта да начальстваның ул мәсьәләгә ничек караганны сорап тормаенча, ул һаман элгәреге юлында дәвам итә иде.

Менә шулай Садыйкның һәркөнне сабын берлә юынып, чистарткан итек киеп, вакытында ашап-эчеп, бернәрсә хакында да уйламаенча, һичнәрсә тугрысында тирән кайгылар, тирән шатлыклар хис кылмаенча үткәргән вакытын, бу көне кичәгә, кичәсе иртәгә охшаган гомерен әллә кайдан ишетелгән: «Сугыш!» — дигән тавыш, әллә нинди иттереп тәэсир итеп бүлдерде. Аның күңелендә әллә нинди яңа хисләр уянды. Бу тавыш Садыйкның гына түгел, казарманың астын өсткә китерде. Бөтен солдатның күз алдына үлү-үлмәү мәсьәләсе җанлы кебек килеп басты. Солдатлар аннан-моннан газета эзләргә, газета укырга ябыштылар. Әфисәрләр солдатларга сугышның ничек баруын акрын-акрын бәян кыла башладылар. Әүвәл көннәрдә әфисәрләр бу сугышмыни, өч атнага да бармас, менә Япониянең бер очыннан икенче очына чыгарлар дип сөйләсәләр дә, бара-тора сакланып сөйли башладылар. Әүвәлге җиңелү солдатларда курку хисен уятты. Андагы солдатларның җиңелүенә түгел, үзләренә чират җитәр дип курка башладылар. Төрлесе төрле хәйләләр эзли башлады, кайсылары кача башладылар. Садыйкка бу хәбәр бик ачы тоелды. Аның да «начальства»га бинаая кылган мантыйкы урыныннан кузгалды. Ул да бу мәсьәләгә үзенең әтиләрен-әниләрен, Гайниҗамалын бергә кушып уйлый башлады. Ул да начальствага каршы килергә аз гына да нияте булмаса да, сугышка бармый калуны бик зур бәхеткә саный башлады. Ул шуның өчен әфисәргә-фәләннәргә денщик булып керүне дә уйлый башлады. Казарманың бөтен һавасын өмет берлә өметсезлек тутырды. Начальствадан кечкенә генә бер кешенең вакытсыз килүе солдатларның күңелендә әллә нинди фикерләр уянуга сәбәп була башлады. Хәзер казарманың эч тормышы, иптәшләрнең бер-берсенә мөнәсәбәте элгәрегә караганда тәмам үзгәрде. Газеталар укый башладылар. Садыйк та, табигый, шул сугыш мәсьәләсе берлә мәшгуль иде. Ул да хәзер җиңелүнең кем

ягында булуын тикшерә иде. Вакыт үтә-үтә болар шул газеталарга, шул үзара моназарәләргә дә өйрәнделәр. Ул да боларга гади бер эш булып китте. Ул да боларны борчымый башлады. Аларның күз алларында үлү-үлмәү күренеп тормый башлады. Һәрнәрсә гади хөкемен алды. Безнең Садыйк та этиләренә, Гайниҗамалга бәхилләшеп хат язганның соңында тынычланган кебек булды. Ул да артык борчылмаенча гомер үткәрә башлады.

## IX

Сугыш башланудан бер-ике ай үткәч, казарманың халкы сугышка өйрәнебрәк җиткәч, бер якшәмбе көнне Садыйк иптәшләре берлә йөрергә чыкты. Яз көне матур булганга, көн дә бәйрәм булганга, урамда йөрүченең исәбе-хисабы юк иде. Фабрикалар, заводлар, магазиннар ябык булганга, боларның приказчик, эшчеләре шул матур һавадан, шул матур көннән файдаланыр өчен, ләззәтләнер өчен, сасы, тыгыз өйләрен ташлап, иркен-киң урамнарга чыкканнар иде. Һәммәсе дә озаграк шул саф һаваны сулар өчен, озаграк шул матур кояшлы көнне күрер өчен, шул кәефле яз исен иснәр өчен акыртын гына хәрәкәтләнәләр, акыртын гына атлыйлар иде. Зур урамга чыга торган урамнардан чиләктән актарган бәрәңге кебек, төрле төстәге, төрле киемдәге кешеләр агып торганга, зур урамның йөрүчеләре күбәйгәннән күбәя бара, тротуарлар тыгызайганнан тыгызая бара, хәрәкәт акыртынланганнан акыртынлана бара иде. Монда поляклар, еврейләр, немесләр, руслар, татар солдатлары — барысы да үз теле берлә сөйләгәнгә, барысының да тавышы бергә кушылып һавага күтәрелгәнгә, шәһәр өстендә әллә нинди кытай музыкасы төсле бер тавыш гөрләп тора иде.

## X

Садыйкның бу эше, Садыйкның иптәшләре карашында, Садыйкның бу егетлеге казармада бик күп сүзләргә сәбәп булды. Казарма халкы Садыйкның бу эшен төрлесе төрле яктан карап, төрлечә мәгънә бирделәр. Садыйкка төрлечә кыйммәт куйдылар, Садыйкның фикердәшләре, иптәшләре, әлбәттә, Садыйкның бу эше өчен Садыйкны каһарман (герой) дәрәҗәсенә мендерделәр. Садыйкны һәрвакыт чын солдат дип мактый башладылар. Башка солдатлар Садыйкның бу эшен ерткычлыкка хисап итеп, Садыйкка бик начар күз берлә карый башладылар. Алар Садыйк берлә сөйләми башладылар. Сөйләгән вакытларында Садыйк тугры килсә, сүзләрен икенчегә бора башладылар. Садыйк берлә иптәшлек мөнәсәбәтен тәмам кистеләр. Һәр нә исә, аны кайсы солдатлар бик егеткә санап, кайсылары аны бик кабахәт ерткычка санап, аны прастуй солдат арасыннан чыгардылар. Ул хәзер казарманың герое булды. Әллә никадәргә чаклы казарманың низаглары, кычкырышлары Садыйкның исеме, Садыйкның эше тирәсендә әйләнде, начальства да Садыйкның бу эшен илтифатсыз калдырмады. Ул да Садыйкка егетлеге өчен «спасиба» диде. Садыйк, әлбәттә, бу сүздән соң, аның иптәшләренең күз карашыннан бу зур «дәрәҗә»дән соң, башын тагы бер караш күтәрде. Ул хәзер үзен-үзе чынлап та прастуй солдат түгел, падишаһка, мәмләкәткә хезмәт күрсәткән солдат дип хисап итә башлады. Начальствага тагы яхшы күренер өчен ул, теге, моның эшен яратмаган солдатларны шымлый башлады. Аларның ни эшләгәннәрен тикшереп, берәм-берәм генә началъствага әйтеп тора башлады.

Аның сүзе берлә казарманың Садыйкны яратмый торган солдатлары арасыннан өч солдат арестовать ителгәч, Садыйкның үзенә карашы тагы ныгайды. Ул үзенең аяк астындагы җирнең бик нык икәнлеген хис итте. Үзенең бара торган юлын бик тугры дип тәмам ышанды.

Озак үтмәде, шундый демонстрацияләрдә начальства Садыйкны ун-унбиш солдатка баш итеп җибәрә башлады. Садыйк, әлбәттә, начальстваның сүзен хәрефе-хәрефе берлә тутырганга, тагы «спасиба»лар ала башлады. Берникадәр рәхмәтләр алганның соңында Садыйк егетлеге, батырлыгы өчен

«крест» та алды. Солдатларның бертөрлесе Садыйкка кызыгып карый башладылар. Садыйк үзе дә башы күккә тигән кебек булды. Ул, ул крестны бик кадерләп кенә тотып, бик мәшәкатьләнеп, ялтыратып, шинельның иң күренә торган урынына гына тегеп куйды. Шуннан соң шинелен дә кадерләп элеп кенә тота торган булды. Аның шул крестка караган саен шатлыгы арта барды. Аның күз алдына авылы, авылларының егетләре, кызлары күренде. Ул үзен-үзе шул егетләр арасында ялтыраган җиз крест таккан солдат киемендә итеп фараз кылды. Аңарга моның бу крестына бөтен авыл егетләре исләре китәр, иске солдатлар көнләрләр, авыл кызлары барысы да шуның тугрысыннан гына сөйләрләр кебек булды. Ул өенә дә, Гайниҗамалга да бик шәп иттереп үзенең крест алуыннан хат язды. Ул әтиләреннән угылларының шул зур дәрәҗәсенә шатланып хат килер, Гайниҗамал да тагы үзенең сөйгәненең шундый зур кеше булуына бик шатлануын белгертер дип, хат көтә башлады. Ләкин әтиләреннән, аның урынына, кара сыерның эче китеп үлүе хәбәрен, Гайниҗамалдан үзен Фәхри малаена соравы хәбәрен ишетте. Садыйк аларның шундый зур эшкә әһәмият бирмәүләренә, медаль шикелле медаль алуны кечкенәгә санауларына, әлбәттә, кәефе килмәде. Шулай булса да: «Алар мужик шул, алар начальстваны белми шул! Алар медальне белми шул!» — дип күңелен юатты. Шулай итеп, Садыйк медальле көенчә Лодзяда тора башлады. Аларга, аларның полклары сугышка җибәрелмәве, Лодзяда охрана өчен калдырылуы белдертелде. Садыйк, шулай итеп, еш патрульга чыгып, демонстрацияләрне таратырга барып гомерен үткәрә башлады. Озак үтмәде, сугыш бетү хәбәре килде. Садыйкның да срогы тулып, кайтырга вакыт җитә башлады. Садыйк та хәзер авылга яңа казаки, яңа шинель, ялтыраган итек, крест-медаль тагып кайтып, авылның исен китерүен уйлый башлады. Озак та үтмәде, вакыйга Садыйк әтиләреннән: «Мылтыгым сынды, түләргә кырык биш сум акчам булмаса, тагы ике ел солдатта калдыралар»,—дигән хат берлә акча алып, яңа шинель, яңа казакиләр, ялтыраган итекләр киеп, ялтыраган җиз крестны тагып өйгә таба юлга чыкты.

## XI

Авыл Садыйкка тәмам үзгәргән кебек күренде. Аның өйләре, тәрәзәләре, ишекләре кечкенәләнгән, урамнары тарайган, атлары-сыерлары, сарыклары вагайган да, кешеләре картайган кебек күренде. Вакыйган да, авыл үзгәргән иде. Баласыз кешеләр балалы булган, сакалсызлар сакаллы булган, сакаллылары карт булган, яшьтәш егетләре өйләнгән, ата булган, яшьтәш кызлары кияүгә китеп беткән. Бу киткәндә бала гына калган кызлар кыз булып тәрәзәләренә кызыл яулыклар корып кич утыра башлаган. Моның алдында борыныннан маңкасы аккан малайлар егет булып җырлап йөри башлаганнар. Әллә нинди күрмәгән, ишетмәгән балалар берлә урамнар да тулган иде. Моңарга башка, авылның борынгыдан калган тау астындагы мунчалар янындагы иске мәдрәсәсе дә ватылган. Аның урынына мәсҗед мәйданына кызыл нараттан зур иттереп, тимер берлә ябып мәдрәсә салынган иде. Садыйкларның йорты да үзгәргән иде. Садыйкның энесе Закир юан гына, таза гына бер кызга өйләнгән — Садыйкның атасы тәмам бөкре карт хәлен алган, анасы килен берлә бертуктамаенча оршыша торган карчык булган иде. Садыйкка ул көнне боларның барысы да ят төсле күренде. Аңарга бу кечкенә өйдә тору, бу кечкенә ишекләрдә башны бәрә-бәрә йөрү, бу сасы тирес исе килә торган мужиклар берлә гомер итү, бу начальствасыз халык берлә эш итү авыр булыр төсле тоелды. Ул эченнән генә үзенең казармасын, үзенең иптәшләрен, үзенең ңачальствасын сагына башлады. Тагы күрешергә килгән карендәш-кабиләнең, дуст-ишнең моның күкрәгендәге ялтыраган медаленә илтифат итмәүләре, аны күрмәгән кебек, берсенең дә ни өчен бирделәр дип сорамаулары моның ачуының кабаруына сәбәп булдылар. Ул аларның наданлыгы өчен, аларның хезмәт кадерен белмәве өчен кәефе китә башлады. Авылда үзгәрмәгән нәрсә булса, ул да Гайниҗамал иде. Гайниҗамал һаман элеккеге кебек тулы, һаман элеккеге кебек ачык, һаман элеккеге кебек Садыйкны сөя иде. Шуның өстенә Гайниҗамал Садыйкны бик сагынган, аңарга сөйләр өчен, әллә никадәр сүзләр хәзерләп куйган иде. Бу юлы алар бик озак сөйләштеләр, бик озак сөештеләр, берсе-берсенә ничек гомер

үткәрүләрен энәдән җебенә кадәр сөйләделәр. Садыйк, әлбәттә, үзенең «спасиба» алуын, медаль алуын бик озын итеп сөйләде. Ләкин Гайниҗамал да аның «спасиба»сына, аның медаленә аз гына да әһәмият бирмәде. Садыйк эченнән генә моңарга да «мужик» дип куйды. Садыйк үзенең тиздән этиләренә әйтеп Гайниҗамалны соратачагын сөйләп, Гайниҗамалга алып кайткан бүләкләрен биреп кайтып китте. Икенче көнне Садыйк авылны йөрергә чыгарга уйлады. Әүвәл бик яхшы иттереп итеген чистартты, бик озак иттереп шинельләрен, казакиен йоннан, мамыктан әрчеде. Медален ялтыратты, аның соңында кәкәшне кәкре генә киеп, көяз-көяз басып урамга чыгып китте. Ул урамдагы кешеләр берлә күреште. Күкрәген киереп кенә сөйләште, сорашты. Ләкин берсе дә медаленә илтифат итмәде. Берсе дә ни өчен алдың дип сорамады. Авыл урамнарын йөреп бетергәч, күп кешеләр берлә күрешкәч, кайтырга борылды. Түбән очтан борылып, су аша чыгып, аргы яктан кайтмакчы булды. Начар юллардан карга бата-бата, мондагы юлны Лодзя юлы берлә чагыштырып, мондагы былчырактан кәлешкәлә өенә таба борылды. Шул арада булмады, артыннан ручса: «Тукта!» — дигән тавыш ишетте. Әйләнеп караса, бер әллә нинди стражникмы, урәтникме күрде. Стражник, урәтник берлә эше юклыгын белгәнгә, Садыйк, башкага кычкыра дип, тагы баруында дәвам итте. Теге тавыш катырак иттереп: «Әй, солдат! Тукта!» — дип кычкырды. Садыйк, ни бар, дип, туктады. Урыс килеп җитеп: «Ник тукта дигәч туктамыйсың? Син кем булдың?» — дип сүгенергә тотынды. Тагы шуның өстенә: «Син кем? Кайдан килдең? Кая барасың?» — дип сорарга тотынды. Садыйк моның үзе берлә шулай илтифатсыз кылынуларына бик ачуы килеп: «Син миңа кычкырма, мин синнән куркырдай түгел. Миндә ни эшең бар?» — дип китә башлады. Теге тагы туктап: «Исемең кем?» — дип сорарга тотынды. Боларның бу низагларын шунда капка төбендәге бер кеше килеп өзде. Ул урәтниккә: «Бу безнең авылның солдаты, кичә генә кайтты», — диде. Урәтник Садыйкка карап, ачуланган тавыш берлә: «Син бик шәбәймә, мин сине өйрәтермен!» — диде.

Садыйк бик ачуы килеп: «Мин синнән куркардай түгел», — дип китеп

барды. Үрәтник: «Юк, куркырсың! Өйрәтермен!» — дип, книгәсен чыгарып, теге кешедән Садыйкның исемен, атын сорап юлына юнәлде. Садыйк шул ачу килүе берлә өенә кайтты. Өйгә кергәч, бик көлеп-көлеп: «Мине куркытмакчы була, мин медаль алган!» — дип, үрәтник берлә очрашканын сөйләде. Әтисе куркып китеп: «Каршы сөйләмә, менә шуның сүзе берлә әле мөгаллимне алып киттеләр. Төрмәдә ята. Яңы мулла да коты очып кына тора, каршы килгәнне бер дә яратмый», — диде. Садыйк: «Мин аңарга исе китәрдәй түгел, мин андыйларны күргән», — дип чыгып китте. Озак үтмәде, Әхмәди абзый, шатлыктан, муллалар кертте. Муллалар мәҗлесендә муллалар сөйләмәенчә генә ашап-эчеп мәҗлесне үткәрделәр. Аштан соң чәйгә алып калгач, Садыйк муллаларга: «Мулла абзый, син элгәре сөйләп утырырга ярата идең, хәзер картайгансың ахрысы», — диде. Карт мулла: «Хәзер замана башкарды. Элгәре ни теләсәң, шуны сөйләргә ярый иде. Әле менә мөгаллимемезне шул юк сүз берлә алып киттеләр бит», — диде. Садыйк та үзенең урәтник берлә сөйләшүен һәм дә үрәтниктән курыкмавын сөйләде. Тагы мөгаллимне ник алып китүләрен сорашты.

Муллалар: «Хәзер шундый мода китте, куштаннар барып әйтә дә, «внутренни врак» дип алып китәләр», — диде. Садыйк боларның баяннарыннан эченнән генә көлеп: «Монда «внутренни врак» булмый, менә безнең тегендә поляк, еврейлар — «внутренни врак», — диде. Икенче бер кеше: «Менә шул мөгаллим җир тугрысында бик күп сөйләде, халыкның җире юк дип, халыкны җирле ясарга тырышты. Шуны үрәтниккә барып әйттеләр», — диде. Садыйк: «Җир тугрысыннан сөйләргә ярамый димени! Авыл халкы җирсез ничек торсын»,— диде. Шундый сүзләр берлә чәй үтте, муллалар таралдылар. Үрәтниккә моның сүзләрен барысын да әйтеп тукыдылар. Ул да үз тарафыннан Садыйкны шымлап йөри башлады.

## XII

Садыйк кайтканнан атна да үтмәде, Садыйкка Гайниҗамалны килештеләр. Әхмәди абзыйларда да, Гайниҗамалларда да туй яраклары карала башлады. Садыйк этисе берлә, шәһәргә барып, Гайниҗамалга әдрәс камзуллык, төлке аягы эчлек, күлмәкләр, читек-кәвеш, шәлләр алып кайттылар. Садыйкның әнисе үзенең карындыкка төреп, солы эченә тыккан казларын, он эченә күмгән йомыркаларын алып, туй ашларын пешерергә хәзерләнә башлады. Гайниҗамаллар машиналы тегүче кертеп, камзуллар тектерә башладылар. Әхмәди абзыйлар да тегүче кертеп, Садыйкка казаки, камзул, тагы Әхмәди абзыйга тун тышлаттылар. Ике йортның бөтен көч-куәте туйга хәзерләнергә сарыф кылынды. Кодалар арасында ашка йөрешү, кунакка барышу башланды.

Вәгъдәдән соң атна-ун көн үткәч, Әхмәди абзыйлар кода-кодагыйны кунакка алдылар, тирә-күрше, дуст-ишне чакырып, мәҗлес кордылар. Садыйкның бабасы берлә әбисе, дүрт кич кунак булгач, икенче атнаны дүшәнбе көн Әхмәди абзый берлә кодагыйны, килен күрендерергә чакырып, өйләренә киттеләр. Вәгъдә җиткәч, Әхмәди абзыйлар да кунакка киттеләр. Алар да дүрт кич кунак булып, Садыйкка бик күп бүләкләр алып, тагы ике атнадан никяхка вәгъдә алып өйгә кайттылар. Садыйк бу көннәрдә дә Гайнаҗамал берлә бик еш-еш күрешә торды. Ул этиләренә әйтмәенчә генә Гайниҗамалга йон күлмәк тә алды, кияү бүләкләрен дә этиләре кушканнан күбрәк алып кайтты. Менә туй якынлашты, ике йортта да туй ашлары хәзерләнеп бетте. Садыйкның анасы сумсалар, сытымбы катламалар, казлар пешереп сандыкка төяп куйды. Садыйк та мыекларын төзәтеп, кияү бүләкләрен кечкенә сандыкка төяп бикләп алды. Муллалардан да дүшәнбе көн өйләдән чыгуга никях мәҗлесенә вәгъдә алынды, һәр эш тәмам булды. Садыйк, Гайниҗамал берлә кияүле-бикәчле булып йөрүне, аннан соң ирле-хатынлы булып торуны уйлап, ләззәтләнә башлады. Ул шул көнне зур бер бәйрәм итеп көтә башлады. Көннәр аңарга бик озак үткән кебек була башлады. Дүшәнбе көн бик озын булса да үтте. Ул бүген кич берлә Гайниҗамал янына барып бик озак утырып кайтты. Якшәмбе дә үтте. Ул: «Менә иртәгә туй була!

Никях укыйлар, миннән сөенче алырга киләләр, кияү алырга киләләр. Мылтыклар атып, кыз катына китәм», — дип уйларга, үзенең шул уйлары берлә ләззәтләнергә, үзенең матур киләчәге өчен шатланырга тотынды. Ул кияү булып кергәндә атар өчен мылтыкмы, мушкатанмы эзләргә китте. Бер аучыдан мылтык алып кайтты. Энесе Закир, эшкә ярамый дигәч, тагы чыгып, сатучы Фәиздән порохлары-ниләре берлә мушкатан алып кайтты. Кич булды, барысы да яттылар. Ул да бүген Гайниҗамал катына бармаенча йокларга ятты.

Азмы-күпме вакыт үткәндер, бик каты ишек дөбердәтүгә Садыйк уянып китте, ул ара да булмады, түрдә әнисе ут алды, ишек ачылды, тыштан әллә никадәр стражниклар берлә урәтник килеп керде. Садыйк, бу ни икәнен аңламаенча, сикереп торып киенергә тотынырга өлгерә алмады, стражниклар, аны чорнап алып, янындагы әйберләрен тенти башладылар. Садыйкның атасы калтырарга тотынды, әнисе егларга тотынды, стражниклар кызу-кызу эзләргә тотындылар, шүрлектән бик күп иске китаплар табып, барысын да алдылар. Садыйк кинәттән булган бу эштән шулкадәре исе китте. Ул катып калып бер сүз әйтә алмады. Ул эчендәге салкынлык, бу стражниклар берлә тыштан кергән суык берлә дер-дер калтырый башлады. Менә озакламадылар, ишек башыннан кичә китергән мушкатанны, порохларны таптылар. Сәке астыннан мылтыгын өсте-рәп чыгардылар. Үрәтник боларны күргәч, Садыйкка карап: «Әйдә, киен, тиз бул!» — диде. Бу сүз карт берлә карчыкка яшен уты кебек тәэсир итте. Карчык кычкырып еларга тотынды. Әхмәди бабай белер-белмәс русчасы берлә, иртәгә туй дип, әллә ниләр бутарга тотынды. Үрәтник бер сүз әйтмәенчә Садыйкка: «Тизрәк! Тизрәк!» — дип, озакламады Садыйкны җилтерәтеп алып чыгып киттеләр.

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Кличка (перекличка)* — исемлек буенча барлау.

*Ядка алу* — ятлау.

*Нутренни врак ( внутренний враг )* — эчке дошман.

*Наразыйлык* — канәгатьсезлек.

*Инсанның маһияте — хәйване натыйк, ишәкнеке — хәйване саһил* — кешенең асылы — сөйләшә торган хайван, ишәкнең — бакыра торган хайван.

*Тирес* — кире.

*Бинаэ* — таяну.

*Вакыйган* — чыннан да.

*Кәкәш* — солдат баш киеме.

**Солдат.** — Хикәя Казанда Хөсәен Әбүзәрев нәшерлегендә И. В. Ермолаева типографиясендә 1908 елда басылып чыга. 46 бит. Имза: Мөхәммәдгаяз Исхаков. Әсәр 1908 елда автор Архангел губернасы Пинега шәһәрендә сөргендә булганда язылган. «Роман. Беренче җөзьә» дип куелган. «Беренче җөзьә» дигән искәрмәсе әсәрнең дәвамы барлыгына ишарә итә. Әмма дәвамы дөнья күрә алмаган.

Ф. Әмирхан «Әльислах» гәзитәсенең «Яңа китаплар» дигән бүлегендә «Солдат» исемле кечкенә генә рецензия бастыра. Анда мондый юллар бар: «Солдат» һәрникадәр әүвәл язылышында сигез төптән гыйбарәт бер генә җөзьөле роман булса да, нашир әфәнде үзеннән килмәгән сәбәп белән өч төп кадәресен әүвәле җөзьә итеп кенә нәшер иткән. Хода насыйб итеп, бервакыт һавалар алмашынса, йөрәкләрне катырган, җансызландырган суыклар урынына ачык йөзле, җылысы белән бөтен нәрсәгә рух өрә торган «яз кояшы» чыкса, калганы да нәшер ителер вә мин дә тәнкыйтемне язармын. Шуны әйтеп китәргә кирәк ки, әсәр—Гаяз әфәнденең хәзерге чын мәсләкен күрсәтә алырлык әүвәле әсәредер». Реакциянең көчәюенә киная белән Ф. Әмирхан: «...никадәр тәфсилле язарга теләсәм вә никадәр үзеннән килмәгән сәбәпләр белән мөхәрриренең тел очында әйтелми калдырылган сүзләрене әйтергә, язарга теләсәм дә, мин дә үземнән килмәгән сәбәп белән аннан тыелырга мәҗбүрмен»,—ди. *(Әльислах, 1908 ел, 26 октябрь.)*

Ф. Әмирхан сүзләреннән аңлашылганча, әсәрнең өчтән бер өлеше генә

басылган. Китапта, басылган өлешендә, төгәлләнмәгән җөмләләр, күп нокталар очрау да—әсәрнең чыннан да цензура иләгеннән бик җентекләп үткәрелгән булуы турында сөйли.

Ш. Мөхәммәдьяровның 1913 елда язган мәкаләсендә дә «Солдат» хикәясенең Садыйкның хакыйкатькә күзе ачылуы, дөньяга карашы үзгәрүе белән тәмамлануы турында әйтелә. Әмма «солдатка киткән бер татар малаеның Лодзьда поляк вә еврейлар бунтларын бастыруда иҗтиһад итеп, медаль алып кайтып та, 7 нче елларда авылдагы үз өендәге хәлләрне күргәч, моңар кадәр булган дөньяга каршы, җәмәгать эшләрендәге анлаешы үзгәрүене тасвир иткән зур хикәя булганы хәлдә, башка куллардагы каләмнәр илә бозылып, алмаштырылып, ярым-ярты көйгә басылып чыга». *(Гаяз әфәнде.— Вакыт, 1913, 2 май.)*

*Лодзь*—Польшадагы шәһәр.

«*Исагуҗи»*—мантыйкның беренче өлеше (икенче өлеше «Сөлләмел голүм») мәдрәсәләрдә дәреслек булып йөргән.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 1 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 1998. Б. 329-355.
Текстны әзерләүче: Лена Гайнанова